КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2018 ел, 29 декабрь

г.Казань

№ 1305

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында торак урыннар белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2018 ел, 17 сентябрь, 786 нчы карары белән расланган урта һөнәри белем бирү буенча белем бирү программаларын – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 графаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аксубай универсаль технологияләр техникумы» ДАҺББУ»;

2 графаның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт һөнәр көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба – ДБҺББУ)»;

64 пунктның 3 графасында «1,106620» саннарын «1,104244» саннарына алмаштырырга;

67 пунктның 3 графасында «1,187110» саннарын «1,183864» саннарына алмаштырырга;

68 пунктның 3 графасында «1,152325» саннарын «1,151303» саннарына алмаштырырга;

69 пунктның 3 графасында «1,090652» саннарын «1,086713» саннарына алмаштырырга;

70 нче пунктның 3 графасында «1,094192» саннарын «1,093515» саннарына алмаштырырга;

85 пунктның 2 графасында «ДБҺББУ» сүзләрен «ДАҺББУ» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2018 ел, 13 сентябрь, 777 нче карары белән расланган 2019 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның 2 графасында «2018» саннарын «2019» саннарына алмаштырырга;

6 пунктның 2 графасында «2018» саннарын «2019» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин